Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин Р.С. Ибраһимов шикаятенә бәйле рәвештә «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының (6 нчы кушымта) II кисәгендәге «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы алтынчы, тугызынчы һәм унберенче абзацларының, шулай ук тулысынча аталган карарның конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2017 елның 3 октябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы

өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының (6 нчы кушымта) II кисәгендәге «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы алтынчы, тугызынчы һәм унберенче абзацларының, шулай ук тулысынча аталган карарның аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Р.С. Ибраһимов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, яклар — гражданин Р.С. Ибраһимов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты Хокук идарәсенең финанс һәм хезмәт законнары мәсьәләләре бүлеге башлыгы А.В. Токмаков, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы урынбасары Р.М. Шәйхәттаров

аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең хокукый экспертиза бүлеге мөдире М.В. Ляукин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Р.С. Ибраһимов «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карары белән расланган Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының (6 нчы кушымта) (алга таба шулай ук — Административ

регламент) II кисәгендәге «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы 8, 11, 12, 13 пунктчалары һәм 14 пунктчасындагы беренче абзацы, шулай ук тулысынча аталган карар белән аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Административ регламентның 2.5 пункты белән суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге билгеләнгән, шул исәптән: читләштерелә һәм алына торган мөлкәткә хокук бирүче документлар (8 пунктча); читләштерелә һәм алына торган күчемсез мөлкәткә техник паспорт (11 пунктча); читләштерелә һәм алына торган күчемсез мөлкәткә (бәяләү хакы турында) ТИБ белешмәсе (күчемсез мөлкәт читләштерелгән очракта) (12 пунктча); торак урыннарны сату җиреннән һәм сатып алу (алмаштыру) җиреннән аерым шәхси финанс счетлары һәм торак мәйданның йорт кенәгәсеннән өземтәләр (13 пунктча); торак урыннарны сату җиреннән һәм сатып алу (алмаштыру) җиреннән аерым бурычларның булмавы турында белешмәләр (14 пунктчаның беренче абзацы) .

Шикаять эчтәлегеннән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Р.С. Ибраһимов — суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган балачактан I төркем инвалиды булган үзенең бертуган сеңлесенең опекуны һәм ул аның белән Казан шәһәрендәге фатирда теркәлгән, анда аларның милек хокукында өлешләре бар. Моннан тыш, аның опекасына алынучының Татарстан Республикасы Саба муниципаль районындагы йортка милек хокукында өлеше бар. 2016 елга кадәр ул сеңлесе белән Казан шәһәрендә индивидуаль торак йортта яшәгән, анда аның һәм сеңлесенең йортка һәм җир кишәрлегенә милек хокукында һәрберсенең ½ өлеше бар. Мөрәҗәгать итүче өлешле

катнашу шартнамәсе буенча үзенең опекасына алынучы белән уртак милеккә төзелә торган йортта фатир алу өчен җир кишәрлеген сату максатында опека һәм попечительлек органы рөхсәтеннән башка әлеге җир кишәрлегендә урнашкан күрсәтелгән торак йортны сүткән. Җир кишәрлеген сатуга опека һәм попечительлек органы рөхсәтен алу өчен ул теркәлү урыны буенча Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенең опека һәм попечительлек бүлегенә мөрәҗәгать иткән, алына торган мөлкәткә Административ регламентның дәгъвалана торган нормалары белән каралган документларның булмавы сәбәпле, аңа күрсәтелгән рөхсәтне бирүдән анда баш тартылган.

Гражданин Р.С. Ибраһимов Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенең опека һәм попечительлек бүлегенең рөхсәт алу кирәклеге турындагы таләбен нигезсез дип саный һәм шуны билгели: ул таләп ителә торган бөтен документларны, аларның кайберсе яңадан алына торган торак мәйданга караганга, ә ул фатир алырга теләгән йорт әле төзелү процессында булганга һәм төзелештә өлешле катнашу шартнамәсен ул җир кишәрлеген сатудан алынган акчаны кирәкле күләмдә керткәч кенә төзи алганга күрә, опека һәм попечительлек органына тапшыра алмаган.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Административ регламентның дәгъвалана торган нигезләмәләре башка торак урынны алу белән мәҗбүри рәвештә бәйле булган опекага алынучының яшәү урынын үзгәртү шарты белән генә кулланылырга мөмкин, бу исә аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен, шулай ук аның опекасына алынучының конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза.

Моннан тыш, гражданин Р.С. Ибраһимов санавынча, дәгъвалана торган карарны бастырып чыгару процедурасы да бозулар белән башкарылган, чөнки ул рәсми рәвештә татар телендә басылып чыкмаган, бу аның конституциячел хокукларын шулай ук боза.

Эшне тыңлауга әзерләгән дәвердә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы

карар кабул ителә, аның 1.2 пункты белән Административ регламентның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пункты яңа редакциядә бәян ителгән һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегеннән читләштерелә һәм алына торган күчемсез мөлкәткә (бәяләү хакы турында) ТИБ белешмәсе (күчемсез мөлкәт читләштерелгән очракта), шулай ук торак урыннарны сату җиреннән һәм сатып алу (алмаштыру) җиреннән аерым шәхси финанс счетлары һәм торак мәйданның йорт кенәгәсеннән өземтәләр чыгарылган. Ләкин тапшыру тиешлеге мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган калган документлар, атап әйткәндә, читләштерелә һәм алына торган мөлкәткә хокук бирүче документлар һәм техник паспорт, шулай ук торак урыннарны сату җиреннән һәм сатып алу (алмаштыру) җиреннән аерым бурычларның булмавы турында белешмәләр үзгәрешсез калган һәм 2.5 пунктның яңа редакциясендә тиешенчә алтынчы, тугызынчы һәм унберенче абзацларда яңадан күрсәтелгән.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин Р.С. Ибраһимов Татарстан Республикасы Конституция судына булган таләпләренә төгәллек кертә һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ

регламентының (6 нчы кушымта) II кисәгендәге «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы алтынчы, тугызынчы һәм унберенче абзацларын, шулай ук тулысынча аталган карарны аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 17 (икенче өлеш), 18 (беренче өлеш), 19 (беренче өлеш), 24 (өченче өлеш), 28 (беренче өлеш), 29 (икенче өлеш), 39, 49 һәм 59 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; икътисади мөнәсәбәтләр граждан белән дәүләт арасындагы социаль партнерлыкка корыла; Татарстан Республикасында хосусый, дәүләти, муниципаль милек һәм милекнең башка рәвешләре бертигез дәрәҗәдә таныла һәм яклана; милек кагылгысыз, законлы рәвештә булдырган мөлкәтне биләгәндә, аннан файдаланганда, аның белән эш иткәндә милекченең хокукларын чикләү, федераль законда каралган очраклардан гайре, рөхсәт ителми; Татарстан Республикасы законнары рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш; басылып чыкмаган законнар кулланылмый; кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый; закон һәм суд каршында һәркем тигез; Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклауның тигез хокукы гарантияләнә; Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә ирекле күчеп йөрү, яшәү һәм тору урынын сайлап алу хокукы гарантияләнә, бу хокукны чикләүләр федераль закон белән билгеләнергә мөмкин; хосусый милек хокукы закон белән саклана; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше һәм 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы

Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала, бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә.

Шулай итеп, «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының (6 нчы кушымта) II кисәгендәге «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы алтынчы, тугызынчы һәм унберенче абзацлары, аларда каралган опека һәм попечительлек органнарына опекун тапшырырга тиешле документлар хокуктан файдалануга сәләтсез зат милкенә төгәлләнмәгән төзелеш объектларын алу буенча алыш-бирешләр башкарырга рөхсәт итмәгәнлектән; шулай ук тулысынча аталган карар аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм торак законнары өлкәләренә кагылалар. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия

Федерациясе Конституциясенең 76 статьясында каралганча, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла (2 өлеш); Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый (5 өлеш).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 24.2 пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының уртак карамактагы мәсьәләләр буенча әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы хисабына (федераль бюджеттан бирелгән субвенцияләрдән тыш) мөстәкыйль гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләренә опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен хәл итү керә.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 34 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацы нигезендә опека һәм попечительлек органнары булып Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнары яисә, Россия Федерациясе субъекты законы белән федераль законнар нигезендә аларга опека һәм попечительлек буенча вәкаләтләр бүлеп бирелгән очракта, җирле үзидарә органнары тора.

Әлеге закон нигезләмәләрен үстереп, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, аның 1 статьясы нигезендә җирле үзидарә органнарына балигъ булмаган затларга һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләре бирелә. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты белән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча әлеге Закон нигезендә һәм аның нигезләмәләрен үтәү максатында муниципаль хокукый актлар чыгарырга хокукы билгеләнгән.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясындагы 12 өлешенең сигезенче абзацы нигезләмәләре буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнаша.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә караган, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйле 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларына нигезләнгән вәкаләтләрен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә шул исәптән кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча туры килү-килмәвен билгели.

Гавами хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибенә кагылышлы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде инде, ул 2017 елның 23 июнендәге 74-П номерлы карарында шундый нәтиҗәгә килә: норматив хокукый акт текстын Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә генә рәсми рәвештә бастырып чыгару үзеннән-үзе аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныр өчен җитәрлек нигез дип санала алмый, чөнки бу гражданнарга аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карала торган норматив хокукый актның эчтәлеге белән танышу мөмкинлеген тормышка ашыруда объектив рәвештә киртәләр тудырмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды аеруча шуны ассызыклады: Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең конституциячел тигезлеге принцибы кысаларында гавами хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы дәүләт телләренең икесендә дә рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибен һәм тиешле срокларны үтәү мәҗбүри.

Ләкин, эш материалларыннан һәм дәгъва белдерелә торган муниципаль хокукый актны чыгарган орган вәкиле чыгышыннан аңлашылганча, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының дәгъвалана торган карары рәсми рәвештә бары тик рус телендә генә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең документлар һәм хокукый актлар җыентыгының 2014 елның 16 гыйнварындагы 1 (232) номерлы чыгарылышында басылып чыккан һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырылган. Татар телендә исә дәгъвалана торган акт басылмый гына калмаган, ә бөтенләй кабул да ителмәгән.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул иткәндә җирле үзидарә органнары актлары татар телендә дә, рус телендә дә кабул

ителергә тиеш дигән таләпне бозуга юл куелган. Әлеге таләпне үтәү «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы икенче өлеше нигезләмәләре белән каралган һәм турыдан-туры Татарстан Республикасы Конституциясенең җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасының дәүләт телләре бертигез нигезләрдә кулланыла дип билгеләгән нормаларыннан (8 статья) килеп чыга.

Шулай да Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эшне караганда ачыкланган бозулар фактларын формаль билгеләү белән генә чикләнергә ярамый дип саный, чөнки суд үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне башкарганда бер яктан кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашырганда башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозу рөхсәт ителмәвен дә кертеп, конституциячел мөһим мәнфәгатьләр балансын һәм икенче яктан — катнашучылары мәнфәгатьләрендә хокукый мөнәсәбәтләрнең тотрыклылыгын тәэмин итү кирәклеген игътибарга алырга тиеш.

Дәгъвалана торган карарны аны кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының элегрәк кабул ителгән норматив хокукый актларының конституциячеллеген генә түгел, ә әлеге норматив хокукый акт кысаларында гражданнарга күрсәтелгән дәүләт хезмәтләренең законлы булуын да шик астына куярга мөмкинлек бирер иде. Мондый нәтиҗә конституциячел суд эшләрен башкару максатларына каршы килер иде, алар Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы буенча Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, кешенең төп хокукларын һәм ирекләрен яклаудан, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокукый системасында өстенлеген һәм анын

бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итүдән гыйбарәт.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карарын (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы карары редакциясендә) аны кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Моның белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетыннан — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны исәпкә алып — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының карала торган карарын Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телендә кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару бурычы төшерелми.

Әлеге эшне караганда ачыкланган хәлләр яктылыгында Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең норматив хокукый актларын кабул итү һәм бастырып чыгару тәртибен бозуның бердәнбер очрак кына булмыйча, системалы характерга ия икәнлеген һәм асылда урнашкан практикага әверелүен билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

Моңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының, карала торган эш буенча конституциячел суд эше катнашучысы булмаган субъектларны кертеп, игътибарын Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты да, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең башка җирле үзидарә органнары да кабул иткән яки кабул итә торган бөтен актлар мөнәсәбәтендә муниципаль норматив

хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибенә карата законда билгеләнгән таләпне үтәүнең мәҗбүрилеге хакында Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан булдырылган алымнарны хокук куллану практикасында исәпкә алу кирәклегенә юнәлтүне мөһим дип саный («Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 73 статьясы).

4. Татарстан Республикасы Конституциясе кешене, аның хокукларын һәм ирекләрен иң зур хәзинә дип игълан итә һәм — кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләренең турыдан-туры гамәлдә булуыннан чыгып — әлеге хокукларны һәм ирекләрне тигезлек принцибы нигезендә тану, үтәү һәм яклау, аларны халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары буенча һәм Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә гарантияләү бурычын дәүләткә йөкли (2, 27 һәм 28 статьялар). Шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 2, 17 һәм 18 статьяларында да беркетелгән. Моннан тыш, Россия Федерациясе Конституциясе кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен федераль закон белән генә һәм конституциячел төзелеш нигезләрен, башка затларның әхлаклылыгын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында кирәк булган кадәр генә чикләү мөмкинлеген рөхсәт итә (55 статья, 3 өлеш).

Россия Федерациясе Конституция Суды шуны билгеләп үтә: Россия Федерациясе Конституциясенең 40 статьясы (1 өлеш) белән беркетелгән халыкара җәмәгатьчелек тарафыннан (Кеше хокукларының гомуми декларациясенең 25 статьясы, Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 11 статьясы) лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокукның бер элементы буларак карала торган торакка хокукны гамәлгә ашыруга карата торак фонды объектларын биләү, алардан файдалану, алар белән эш итү мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенең 45 (1 өлеш) һәм 46 статьяларында гарантияләнгән әлеге

конституциячел хокукны дәүләт, шул исәптән суд яклавы белән һәркемне тәэмин итәргә тиеш, ул тулы һәм нәтиҗәле булырга тиеш (2010 елның 8 июнендәге 13-П номерлы Карар).

Аерым категориядәге затлар буларак хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга өлешчә генә сәләтле гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатында Россия Федерациясе Граждан кодексы аларга опека һәм попечительлек билгеләүне күздә тоткан, шулай ук аларның мөлкәте белән эш итүнең махсус хокукый режимын керткән (31 статья). Андый хокукый режим үзенчәлекләре «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән, аның нигезендә опекун опека һәм попечительлек органының башлангыч рөхсәтеннән башка үзенә карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданның (алга таба — опекага алынучы) мөлкәтен наемга, арендага, бушлай файдалануга яки залогка бирүгә, опекага алынучының мөлкәтен читләштерүгә (шул исәптән алыштыру яки бүләк итү буенча) кагылышлы алыш-бирешләр башкарырга, опекага алынучының хокукларыннан баш тартуга, аның мөлкәтен бүлүгә яки өлешләргә аеруга сәбәпче булган алыш-бирешләр башкарырга һәм опекага алынучы мөлкәтенең бәясе кимүгә китергән теләсә нинди башка алыш-бирешләр башкарырга, ә попечитель мондый алыш-бирешләрне рөхсәт итәргә хокуклы түгел. Әгәр опекун яки попечительнең гамәлләре опекага алынучы мөлкәтенең бәясе кимүгә китерергә мөмкин булса, опека һәм попечительлек органының башлангыч рөхсәтне бирүе шулай ук башка барлык очракларда да таләп ителә (21 статьяның 1 өлеше).

Опека һәм попечительлек органнарының күрсәтелгән рөхсәтен бирү һәм алу белән бәйле мөнәсәбәтләр гамәлдәге законнар системасында «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларының җайга салу предметына керә һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча административ регламентлар нигезендә гамәлгә ашырыла, аларны эшләү һәм

раслау тәртибе әлеге Федераль законның 13 статьясындагы 14 өлеше буенча җирле администрация тарафыннан билгеләнә (12 статья).

Шуның белән дәгъвалана торган Административ регламент хокуктан файдалануга сәләтсез затларның мөлкәте белән алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү турында карар кабул итү өчен җаваплы органны, рөхсәт алу шартларын һәм срокларын билгели торган оештыру-процедура механизмы булып тора һәм үзенең хокукый табигате һәм асылы буенча сәламәтлек торышы аркасында мөстәкыйль үз хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклау һәм үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаган гражданнарның мөлкәти хокукларын яклауның аерым дәрәҗәдәге гарантияләрен билгеләү кирәклегенә юнәлгән.

Күрсәтелгән Федераль законның 12 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты һәм 14 статьясындагы 6 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча административ регламент структурасы дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын билгели торган кисәктән торырга тиеш, стандарт закон яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеген күздә тота. Тиңдәш таләпләр «Дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау турында» Россия Федерциясе Хөкүмәтенең 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карарында, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарында бар.

Китерелгән нормаларның сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, андый исемлекне билгеләү һәр очракта индивидуаль рәвештә, тиешле хезмәтләр күрсәтеләчәк хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсенә карата гамәлгә ашырыла.

Шулай, опекага алынучының мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт алу мәсьәләләрен җайга салу шул исәптән Россия Федерациясе территориясендә күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвен гамәлгә ашыру белән бәйле мөнәсәбәтләрне регламентлаштыруга юнәлгән «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның гамәлдә булу өлкәсенә керә.

Югарыда күрсәтелгән Федераль законның 14, 18 һәм 21 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләре буенча күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәве турындагы гаризага шул исәптән күчемсез мөлкәтнең тасвирламасы һәм теркәлә торган хокукның төре язылган, хокукның булуын, барлыкка килүен, күчүен, туктатылуын, чикләнүен һәм күчемсез мөлкәтне чикләп торуны билгели торган документлар теркәлергә тиеш; хокукларны дәүләт теркәве өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәве өчен каралган һәм тиешенчә кирәк булган башка (өстәмә) документлар да соратылырга мөмкин.

Димәк, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителгән Административ регламентның опекага алынучының мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен алу өчен тапшыру тиешлеге белән мөрәҗәгать итүче килешмәгән документларның тулы исемлеген, шул исәптән читләштерелә һәм алына торган мөлкәткә хокук бирүче документлар һәм техник паспорт, шулай ук торак урыннарны сату җиреннән һәм сатып алу (алмаштыру) җиреннән аерым бурычларның булмавы турында белешмәләр билгеләгән нигезләмәләр федераль законнарның югарыда күрсәтелгән нормаларыннан килеп чыгалар һәм закон чыгаручы тарафыннан опека һәм попечительлек органнарына йөкләнгән мәсьәләләр контекстында (аның берсе булып опекага алынучылар мөлкәтенең сакланышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тора) андый затларның мөлкәти һәм мөлкәти булмаган шәхси хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен яклауның

өстәмә гарантиясе булып торалар һәм үзеннән-үзе кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган буларак карала алмыйлар.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгеләп үтәргә кирәк дип саный: опека һәм попечительлек органнары кабул итә торган карарлар ирекле төсмергә ия була алмыйлар һәм опекун тапшырган документларның Административ регламент билгеләгән исемлеккә туры килү-килмәвен формаль бәяләүгә генә таянырга тиеш түгелләр. Бу конституциячел хокуклар һәм ирекләрне нигезсез чикләүгә юл куелмас өчен опека һәм попечительлек органнары һәр конкрет очракта, барлыкка килә торган тормыш шартларын бәяләүгә дифференциацияләнгән алымны кулланып, эшкә кагылышы булган бөтен хәлләрне тикшерергә, шул исәптән опекага алынучының торак белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпкә алырга тиеш дигәнне аңлата. Дәгъвалана торган нормаларны башкача аңлату нигезләнмәгән һәм хокуктан файдалануга сәләтсез затларның торак хокукларын яклау өлкәсендәге норматив хокукый җайга салуның конституциячел әһәмиятле максатлары белән ярашмаган булыр иде һәм закон чыгаручының хакыйкый ихтыярына каршы ул башкарган хокукый җайга салу нәтиҗәлелегенең җитди кимүенә котылгысыз рәвештә китерер иде.

Шулай итеп, «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының (6 нчы кушымта)

II кисәгендәге «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы алтынчы, тугызынчы һәм унберенче абзацларының законлы вәкилләр опекага алынучыларның мөлкәте белән эш иткәндә аларның мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә юнәлгән башка нормалар белән системалы бәйләнештә каралучы дәгъвалана торган нигезләмәләре кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яки башкача боза торган буларак карала алмыйлар һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 17 (икенче өлеш), 18 (беренче өлеш), 19 (беренче өлеш), 28 (беренче өлеш), 29 (икенче өлеш), 39, 49 һәм 59 статьяларына каршы килмиләр.

Дәгъвалана торган нормаларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану законнарда каралган торак урын алуның төрле формаларын исәпкә алуны тәэмин итәчәк һәм әлеге өлкәдәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның ачыклыгына һәм ике төрле аңлашылмавына ярдәм итәчәк шундый хокукый инструментларны куллануны күздә тота торган хокукый җайга салуның сыгылмалылыгы принцибы нигезендә опекага алынучыларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга опекуннар тарафыннан рөхсәт алу тәртибен хокукый җайга салуны алга таба камилләштерергә комачаулык итми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә административ

регламентларны раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 номерлы карары (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 5 июнендәге 2094 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган балигъ булган затларның мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының (6 нчы кушымта) II кисәгендәге «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы алтынчы, тугызынчы һәм унберенче абзацларының хокукый нигезләмәләрен, шулай ук тулысынча аталган карарны аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының шул исәптән әлеге Карарда белдерелгән аларга нигезләнгән хокукый позицияләрен исәпкә алып, норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә кабул итү һәм рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибен бозып кабул ителгән һәм басылып чыккан үзләренең муниципаль норматив хокукый актларын яңадан карарга тиешләр.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән

басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 75-П**

**Татарстан Республикасы
Конституция суды**